**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 283-34 «28 » май 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2022 елның 14 декабрендәге 186-20 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карары белән расланган "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларның, контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турындагы 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы
карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2022 елның 14 декабрендәге 186-20 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карары белән расланган "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларның, контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1 бүлекнең 1.5 пунктында «12 688,00» санын «13 323,00» санына алмаштырырга;

3.2 3 бүлекнең 3.2 пунктындагы 5 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларның, контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карар 2024 елның 01 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы 2024 елның 28 маендагы 283-34 номерлы карарына кушымта

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларның, контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә 1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль район башлыгы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, контроль-хисап органы рәисе һәм аудиторы айлык акчалата бүләкләү күләме

| Хезмәт өчен түләү төркеме (муниципаль берәмлекнең халык санына карап) | Хезмәт өчен түләүнең 4 нче төркеме |
|---|---|
| Вазыфаи оклад (сумнарда) | |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 37 037 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 33 331 |
| Депутатлар | 17 950 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 15 256 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 33 331 |
| Контроль-хисап палатасы аудиторы | 24 248 |